*МӨНӘҖӘТ*

# Өзелде өметләрем

**(Балаларын югалткан әниләргә багышлыйм)**

*Ямьле җәйләр үтеп, балам,*
*Килде моңсу кара көзләре.*
*Бик сагындым, йөрәк парәм, сине,*
*Төшләремә бүген кер әле.*

*Аердылар, балам, сине миннән*
*Усал җилләр, ачы бураннар.*
*Син кайтканда чәчәк ата торган*
*Корыдылар кызыл яраннар.*

*Бар җылымны биреп үстердем дә*
*Сакладым мин сине салкыннан.*
*Хәзер, балам, син минеке түгел,*
*Ала алмыйм җирнең куеныннан.*

*Ул мәңгегә мине мәхрүм итте,*
*Күзем ачсам, дөнья караңгы.*
*Бала назы, ана бәхетеннән*
*Ник икән соң Ходай аерды?*

*Тәрәз буйлап йөрим иртә-кичен,*
*Күзләрем дә һаман яңгырлы.*
*Күңелләрем тулы, һич җылынмый*
*Йөрәккәем каты, гел карлы.*

*Ничек кенә түзим икән, балам,*
*Күрми торып матур йөзеңне?*
*"Мин тудым", - дип, елап тавыш биргән,*
*"Әннә" дигән тәүге сүзеңне?*

*Кабереңә барам, үксеп елыйм,*
*Син бик ерак — ишетмисеңдер.*
*Минем кебек күз яшьләре түгеп,*
*Анаң өчен өзелмисеңдер.*

*Кеше елмайганда нишлим соң мин,*
*Елмаюны күптән онытмым.*
*Зәңгәр күлдә йөзгән аккош идем,*
*Кайгы дигән зур күлдә баттым.*

*Бу дөньялар миңа хәзер ямьсез,*
*Җир куенында балам ятканда.*
*Зинһар өчен, мине юатыгыз,*
*Кеше балалары кайтканда.*

*Әй, Ходаем, күр дидеңме инде,*
*Канатымны нигә сындырдың?*
*Газиз балам, йөрәк парәмне син*
*Тар кабергә илтеп куйдырдың.*

*Ул бит ялгыз, анда, япа-ялгыз,*
*Бик өшесә, кем соң җылытыр,*
*Ярсып-ярсып әгәр елап ятса,*
*Миннән башка кем соң юатыр?*

*Сиңа диеп, балам, оекбаш бәйлим,*
*Сандыгыма бик күп җыелды.*
*Ана йөрәге ничек түзсен инде,*
*Оекбаш та хәтта саргайды.*

*Каберләрең, балам, булсын нурлы,*
*Кайтара алмыйм сине яңадан.*
*Рәнҗеп ятма, озын гомер телә,*
*Аермамын изге догамнан.*

*Аналарга телим шуны гына:*
*Бала хәсрәтләре килмәсен.*
*Гомер буе балкып яна торган*
*Күкләреңдә кояш сүнмәсен.*

*Кем югалткан газиз балакаен,*
*Юлларына чәчәк сибегез.*
*Ул — дөньяда иң кайгылы ана —*
*Хәл белергә көн дә килегез.*

**Гөлназ БИЛАЛОВА.**
Бөгелмә шәһәре,
Татарстан.

# Хатын-кыз хокуклары

Ислам күзлегеннән караганда, хатын-кыз – Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең яраткан бәндәсе, аны аңлап, хөрмәт итеп, саклык белән карарга кирәк.

Еш кына җәмгыятьтә хатын-кызның ир кеше белән тигезлеге хакында бәхәсләр ишетергә туры килә. Исламда мондый сорау-бәхәсләр урынсыз, чөнки ир белән хатын ярышып түгел, бер-берсен тулыландырып (һәм физик, һәм психологик яктан) яшәргә тиеш. Хатын-кыз һәм ир-ат җәмгыятьтә төрле җаваплылыкта.

Исламдагы хатын-кыз табигате белән замана тенденцияләренә ияреп, мөстәкыйль фикер йөртергә, һөнәри үсеш һәм гаиләдәге башка мәсьәләләрне чишкәндә ирләр кебек эшләргә тели. Мондый «ялган» иреклелек – күп хатын-кызлар шуңа омтыла да – еш кына тормыш (гаилә) нигезен җимерүгә китерә.

Коръәндә һәм хәдисләрдә хатын-кызның бурычы һәм хокуклары язылган.

Шуларның берничәсенә күз салыйк.

1. Ислам ир белән хатынга яшәешне дәвам итү өчен әти-әни булу бурычын йөкли.

*«Әй кешеләр! Хакыйкатьтә Без сезне ир белән хатын итеп, халык һәм кабилә итеп яраттык, сез бер-берегезне белсен өчен...»* («Әл-Хуҗурат» сүрәсе, 13нче аять.)

Хатын-кыз күңел кичерешләре, сизгерлек, кайгыра белү һәм үзен кем өчендер корбан итә белү белән бүләкләнгән. Ул Әни булырга хаклы һәм мондый мөмкинлек ир-атка бирелмәгән.

Әни булу мөһим һәм мәртәбәле күренеш. «Җәннәт ачкычы – әниләр аяк астында», – дигән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Хатын-кыз ире тарафыннан ихтирамга лаек. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатынына әйбәт мөнәсәбәттә булган ирнең иманы камилрәк», – дип әйткән.



һәркем үз тәнен каплап йөрергә тиеш. Оялчанлык хатын-кызларга гына хас сыйфат булырга тиеш, дигән ялган фикер булмасын иде. Безне ахирәттә бәхеткә илтүче бу сыйфат Аллаһының барлык колларында булырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәмугта янучы хатын-кызларны күрүен сөйли. Алар тумыштан оят дигән хистән мәхрүм булган, шуңа күрә җәннәтне күрү түгел, исен дә исни алмыйлар, ди. Киемнәре шәригатьчә булмаган бу асыл затлар тәмугта күеп каралган була. Алар үзләре ярым шәрә йөрү белән генә чикләнмичә, башкаларны да мондый гөнаһка өндәүчеләр.

Иман һәм оят бер-берсенә бәйле. Берсе кимесә, икенчесе кими, бер сыйфат бетсә, икенчесе дә юкка чыга.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Иман һәм оялчанлык – ихлас кешенең нигезе. Бу ике сыйфат бер-берсен тулыландырып тора»,* – ди. Пәйгамбәребез шулай ук: *«Оялчанлык хисе иң беренче кеше – Адәм галәйһис-сәламгә хас булган, һәм ул бу хис белән гөнаһтан сакланган»,* – ди. «Оятың качса, теләсә нинди гамәл кылырга сәләтле буласың», – дигән әйтем дә меңнәрчә ел яшәп килә.

**Сәрия ЗАКИРОВА.**
*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Мөселман алдында мөселманның хокуклары

Мөселман кеше белән очрашканда сәлам бирегез һәм ике кул белән күрешегез. Каядыр чакырганда, каршы килмәгез. Төчкергәндә сәламәтлек теләгез, авырган кеше янына барыгыз. Үлгән кешене соңгы юлга озатыгыз. Мөселман кеше берәр яхшы эш эшләвен сораганда: «Ант итәм, эшләрмен», дисәгез, вәгъдәгездә торыгыз. Аны яман хәлләрдән саклагыз. Киңәш бирегез. Тәкәббер булырга ярамый, тыйнак сөйләшегез. Ул сөйләгәнгә каршы сөйләп, кәефен кырмагыз.

Ике арада низаг булганда, мөнәсәбәтләрне өч көннән артыкка өзәргә ярамый. Әгәр низагтан соң берәү, низагны онытып, икенче мөселманга: «Сәлам!» дисә, ул - әдәпле, яхшы кеше. Диндәшегезгә начарлык теләмәгез. Үзегез белән нинди мөгамәләдә булуларын теләсәң, аның белән дә шундый мөгамәлә кыл. Яхшы гамәл кылган кешегә ярдәмгә килүче мактала. Начар гамәл кылучылар өчен Ходайдан гафу үтенегез. Гөнаһлы мөселманнарга дога кылыгыз, гыйбадәт кылганда тәүбәләрен кабул итүен теләгез.

Һәр мөселманга игелек кылырга әзер булыгыз, шулай ук бар кешегә дә игелек кылырга кирәген онытмагыз. Өлкәннәрне ихтирам итегез, кечеләргә кечелекле булыгыз, елмаеп сәлам бирегез, вәгъдәләрегезгә тугры булыгыз. Абруйлы мөселманнарга ихтирам белдерегез, аларга ышаныгыз һәм аларның изге эшләрен хуплагыз, изгелек кылырга теләүчеләргә үзегез белгән белемнәрне өйрәтегез.

Мөселманнар арасындагы конфликтларны җайга салырга тырышыгыз. Уйланылмаган эшләр эшләмәгез: башка мөселманнар күңелендә шик һәм ышанмаучылык тудырмагыз, аларны гөнаһландырмагыз. Мөселманнар эшләргә ниятләгән нәрсәләрне башкарырга булдыра алган кадәр булышыгыз. Мөселманнарның милкен, яхшы атын һәм үзен якларга әзер булыгыз.

*(«Татар мөселман календаре»ннан)*

# Мунча әдәпләре

Безнең бүгенге сүзебез кешенең үзенең тәненә карата ислам динендәге нормаларны аңлатып үтү. Мөселман кешесенең иң уртачасы атнага бер мәртәбә мунча керүе бик яхшы гамәл. Кызганычка, безнең халык ял көне якшәмбе булу сәбәпле мунчаны шимбә яга. Ләкин безнең ата-бабаларыбыз мунчаны пәнҗешәмбе кичен якканнар. Ислам дине буенча көн кояш баткач башлану сәбәпле, мунча керү дә җомга көн кергәч кенә булып чыккан, ә бу - бик әҗерле гамәл.

Шушы уңайдан җомга алдыннан госел алуны да искә алып үтәсе бар. Госел алуның тәртибе бик гади – ул иң беренче җенси әгъзаларны һәм арт юлны юу. Ислам әдәбе буенча бу әгъзаларны сул кул белән юарга кирәк. Шулай ук әгәр ул урыннарда һәм култык астында йон үскән икән, аны кыру - шулай ук пакьлекнең берсе. Кырырга куркынычлык янаганда хәзерге вакытта депиляцион кремнар да сатыла, нечкә урыннарда аларны куллану уңай. Бу урыннарны кырганнан һәм юганнан соң, кулларны яхшы итеп юып, авызны һәм борынны чайкарга. Моннан соң баштан тотынып аякка кадәр су белән коенырга. Су тәннең барча урыннарына тиеш, ягъни коры урыннар калмаска тиеш. Шулай итеп, госел коенган булып санала. Госел якынлык кылганнан соң, төшләнгәннән соң, хатын-кызларның айлык каннары туктаганнан соң һәм бала туганнан соңгы каннар туктаганнан соң, мәҗбүри рәвештә коенылырга тиеш.

Мунчага сул аяк белән атлап керәләр. Мунчага кергәнче дога кылына. Бу дога шулай укыла: *«Бисмилләһи, Аллааһүммә иннии әгүүзү бикә минәл хубүси үәл хабәә-иси».* Аның мәгънәсе түбәндәгечә: «Аллаһының исеме белән, Аллаһым, тәхкыйк мин Сиңа бозыклык иясе булган ир һәм